**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены карары**

**14.11.2020** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

-балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм аны Үзәк урамга урнаштыру;

-Яшьләр урамындагы балалар мәйданчыгын әйләндереп алу өчен койма сатып алу һәм аны урнаштыру;

- торак пункт эчендәге юлларны өлешчә ремонтлау һәм вак таш җәю;

- чәчәк утырту өчен савытлар сатып алу;

- мәгълүмат стендлары сатып алу ;

-яңа елга яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;

- елга аша күперчекне ремонтлау.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары Шепкә
авыл җирлеге башлыгы Камалиева Л.М.